ТАТАРСТАН
ВЕТЕРАНЫ

№ 12
29 октябрь, 2022 ел

РЕСПУБЛИКА ВЕТЕРАННАРЫ (ПЕНСИОНЕРЛАРЫ) ТӨБӘК ИҖТИМАГЫЙ ОЕШМАСЫ СОВЕТЫ ҺӘМ «ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН» ГАЗЕТАСЫНЫҢ УРТАК КУШЫМТАСЫ

МАТУР КАРТЛЫК

Нигъмәтулла Абдуллин тормыштан зарланмый

> 2

ИРЕМ ХАРИС

Еллар үткән саен сагындыра

> 3

ҖЫРЛАП ЯШИК!

«Балкыш» фестиваленнән фоторепортаж

> 4

ҮЗЕМ БҮЛӘК МИН!

Пар канатлар

Апаста яшәүче Наилә һәм Фәрит Кәлимуллиннар һәркемгә үрнәк булып 55 ел парлы гомер кичерә. Бер-берсенә терәк, ышаныч, балаларына кайгыртучан әти-әни, күрше-күлән, туган-тумача, дус-ишләре арасында олы хөрмәткә лаек пар алар.

– 1967 елның 10 августында – үземнең туган көнемдә – Наилә апагызны, бик зурлап, Болын-Балыкчыдан Иске Әнәлегә алып кайттым. Авыл халкы аны үз итеп каршы алды. Әле дә хәлләрен белешеп торалар, – ди Фәрит абый.

Гаилә башлыгының сүзләрен тулыландырып: «Һәр туган көн саен аңа мин – бүләк», – дип шаярта Наилә апа.

Фәрит абый җитәкче урыннарда эшләсә, Наилә апа гомер буе яшь буынга белем һәм тәрбия орлыклары өләшкән. Фәрит абый әле дә өйдә генә утырырга тырышмый. Ул Россия Пенсионерлар берлегенең район оешмасын җитәкли. Өлкәннәр мәнфәгатен кайгыртып, төрле чаралар, сәяхәтләр оештыруга үз өлешен кертә. «Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре» исеменә лаек. Үзешчән сәнгатьне үз итеп яши, моңлы җырларыннан аерылмый. Комсомол комитетында, районның финанс, райкомның пропаганда, мәдәният һәм Пенсия фонды бүлекләрендә эшләгән елларын сагынып искә ала.

> 3

Хәбәрләр

Егетләргә – оекбаш

Зәй районының Имәнлебаш авылы әби-апалары мобилизацияләнгән ир-егетләргә җылы оекбаш, бияләйләр бәйләгән. Алар, һәр көн саен мәдәният йортына җыелып, йон эрләү эшен башлап җибәргәннәр. Апаларның бер төркеме йонны яза, икенче төркеме кабалар белән эрләп утыра. Бәйләнгән әйберләр солдатларга гуманитар ярдәм итеп җибәрелгән. Мәдәният йорты директоры Энҗе Әхмәтҗанова сүзләренә караганда, авыл халкы егетләргә ярдәм итәргә бик теләп кушылган. «Җылы оекбашлар, бияләйләребез аларны салкыннан сакласын. Якташларыбыз исән-сау әйләнеп кайтсын», – ди ул.

Картлар йортында кунакта

Буа районының ветераннар (пенсионерлар) оешмасы вәкилләре күптән түгел картлар йортында булып кайтты. Көмеш волонтер Галина Синьчугова район картлар йортында тәрбияләнүчеләр өчен «Оста куллар» түгәрәге үткәрде. Очрашу бик матур узды. Өлкәннәр тасмалардан, җепләрдән кул эшләнмәле ясады. Әлеге очрашу эшкә осталыкны гына түгел, бер-береңә булган җылы мөнәсәбәтне дә күрсәтте. Картлар йортында тәрбияләнүчеләр райондашларына рәхмәт әйтеп калды.

«Туксан бишемә дә килегез!»

Ютазы районының Акбаш авылында яшәүче хезмәт ветераны Нигъмәтулла Абдуллинга 90 яшь тулды.

Нигъмәтулла ага Акбашта туып-үскән һәм аның бар гомере шушы авылга бәйле. Гаиләдә алар биш бала үскән. Шул чорның барлык балалары кебек үк ул бик яшьли хезмәткә җигелгән, «Ждановский» совхозында өлкәннәр белән беррәттән эшләгән.

1941 елның җәендә, сугыш башланып 1–2 ай узгач, аларның әтисен фронтка алганнар. Әнисе балалар белән ялгызы калган. Берничә айдан соң Саҗидә сеңелләре дөньяга килгән. Тик гаилә башлыгына гына төпчеген күрергә насыйп булмаган, ул яу кырыннан кайтмаган, чит җирләрдә башын салган.

Мәктәптән соң Нигъмәтулла, Бөгелмәдә тракторчылар әзерләү курсларын тәмамлагач, берничә ел тракторда, аннары терлекчелектә эшләгән. Хатыны Мөхәррәмә белән бергәләп өч бала – ике ул һәм бер кыз тәрбияләп үстергәннәр. Уллары Фәрит һәм Фәнис нефть тармагында хезмәт куйган, кызлары Илсөяр укытучы булып эшли. Аларның һәркайсының үз тормышы, гаиләсе һәм балалары бар. Балаларының әтиләрен кадерләп, хөрмәтләп яшәүләре, кайгыртучанлык күрсәтүләре күренеп тора. Өйләрендә чисталык һәм тәртип, җылы һәм якты. Кызганыч, 5 ел элек Нигъмәтулла аганың иңгә иң куеп яшәгән тормыш иптәше вафат булган. Ул аны бик сагына, юксына, әмма яшәү өчен ничек тә көч табарга кирәк, чөнки тормыш дәвам итә.

Өлкән яшьтәге юбилярыбыз бүген дә бик актив: бакчасын карый, бәрәңге утырта, хәтта виноградка хәтле үстерә. Кунакларны ул 95 яшьлегенә дә чакырды.

ДАНИФ ХАННАНОВ:

«КАРТАЙМАСАҢ, ЯШЬЛЕК УЗМЫЙ»

Кайчан гына очрашсаң да, кояш кебек яктыртып торучы ачык кешеләр була. Мин аның шул умарта кортлары кебек өлгерлегенә, очынып йөргәненә сокланам, ни дисәң дә, сигезенче дистәсен түгәрәкләп килә. Бер мәлгә Даниф дус белән тормышның үткән сәхифәләренә сәяхәт кылып алдык.

– Татшуган авылында төпчек – алтынчы бала булып дөньяга килгәнмен инде мин почык борын, – дип сөйләп китте ул. – Әти, мин туганчы ук фронтка китеп, сугыш кырында ятып кала. Апам, абыем да бер-бер артлы вафат булалар. Әлләэ яши, әллә юк дип, исемемне Рәдиф кушып, таныклыкка Даниф дип язып куялар. Авыр сугыш чоры: әнкәй, ике апам һәм тагын бер имгәк – мин. Яшерен-батырын түгел, бу сүзне ишеткәләдем мин, ашау ягы бик кыен булган өчендер. Ике апам чит шәһәрләргә чыгып китә дә, әнкәй белән генә яшәп калабыз. Әнкәйнең һәм аның чордашларының бер сыйфаты – укымыш-белемнәре булмаса да, аларның башларыннан узган тормыш мәктәбе балаларына тиешле тәрбия бирү белән бәйләп бетергесез өлгегә әверелгән. Башкалар янында үзеңне әдәпле тотарга, кеше әйберенә кагылмаска, ялкау булмаска, иртән озак йокламаска, бераз үсә төшкәч, тәмәкегә якын килмәскә һәм башкалар. Әнкәйне беренче тапкыр ныклап сөендерүем мәктәптә башлангыч сыйныфларда укыган вакытларда, «уфалла» арбасы белән кышка җитәрлек итеп мичкә ягарга урманнан агач ботагы ташып куюым булгандыр. Авылның җидееллык мәктәбен тәмамлагач, колхозның сыер көтүен көтәргә булдым. Әле анда 4 кешене бар яклап бик җентекләп сайлап кына алдылар һәм минем анда эләгүем юктан гына түгел иде. Бу әнкәмнең тормышын, аның күңел халәтен бөтенләй яктырту, күтәрү иде дип уйлыйм, чөнки хезмәт хакы әйбер, һәр көтүчегә беркетеп ат бирелә, җитмәсә, аякка ул чорда күп кешедә булмаган кирза итек, өскә брезент плащ эләгә. Без, көтүчеләр, атка атланып, егетләр алдында шактый дәрәҗәле кыяфәт чыгарып йөри идек. Тәүге бүләгемне дә шушында район җитәкчеләре кулыннан алдым. Төймәсенә баскач, ялт ачылып, капкачын япканда тирәдәгеләргә ишетелерлек итеп шалт ябыла торган затлы кесә сәгате иде. Бу көнне клубта колхозның гомуми җыелышы узганы хәтердә. Әзрәк мактап та алдылар: мин сыерлар көткән вакытта сөт саву күбрәк булган икән.

Беренче мәртәбә алган икмәкне келәтләренә кайтарып аударгач, аны Бөгелмәгә механизаторлар әзерләү курсларына җибәрәләр. Башы күккә тия егетнең! Ул вакытта мондый ышаныч һәркемгә дә эләкми бит. Шуннан соң җиде ел трактор һәм комбайнда эшли ул.

– Уракта без гел җиде комбайнчы ярыша идек. Бер көнне колхоз рәисе Нәфис абый Якупов, яныма килеп, башка комбайннарны да үземнеке кебек көйләп бирүемне сорады. Файдасы булды, бөртек югалту нык кимеде, – дип искә ала ул. – Һич көтмәгәндә бригадир итеп куйдылар, колхозга бер бригада, ягъни бөтен эшләр минем карамакта. 1971 ел бу. Ничек өлгерелгән дә, ничек түзелгәндер. Инде айдан артык туктаусыз яңгырлар: терлекләрне ашатырга комбайннар үлән чаба алмый, тәгәрмәчле тракторлар көчкә саз ерып йөри. Абзарда 800 баш сыер малы, көтүдә йөртү дә мөмкин түгел. Сыерларны азык белән тәэмин итү өчен үләнне чалгы белән чабып, арба таккан чылбырлы тракторга кул көче белән төяргә. Моны башкару өчен миңа авылда яхшы чалгылары белән 80 кешелек эшче көче җыярга. Барыбыз да – ир-егетләр, яңгыр астында үлән чабып кайтарып, малларны тәмам ашатмыйча өйгә кайту юк.

Өч ел бригадирлыктан соң аны баш инженер итеп куялар. Бер елны остаханә, икенче елны гаражлар, складлар төзиләр. Машина-трактор паркын ике кат коймa белән әйләндереп, арасына алмагачлар утырталар. Бүген дә яз көне шау ак чәчәкле бу урынны Даниф Ханнанов бакчасы дип йөртәләр. Бик зур эшләр башкарыла ул чорда. «Эконом» район күләмендә иң алдынгы колхозлар сафына чыга. Алдынгы терлекче Мөгелсем Хәйретдинованы РСФСР Югары Советына депутат итеп сайлаталар. Аның ярдәме белән заманча техникалар кайтаралар.

Даниф Ханнанов бер үк вакытта читтән торып Чистай авыл хуҗалыгы техникумын, Казанда институт тәмамлый. 1979 елда «Тырыш» колхозында партоешма секретаре, рәис урынбасары була. Билгеле инде, булдыклы җитәкчене озак тотмыйлар, Даниф Ханнановны 1981 елда Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының механикалаштыру бүленә эшкә чакыралар. Бераз эшләгәннән соң, ул – министрлыкның автотранспорт предприятиесе директоры.

Ул бүген дә иртә таңнан торып, табигать кочагына – умарталары янына ашыгыр, ягъни эшчән бал кортлары белән ярышып-очынып йөрер. Шифалы балларын үзе кебек замандашларына, якынтирәләренә дә өләшеп шатландырыр. Шуңа картая белми Даниф, тынмас йөрәге белән гомере буе яшь күңелле, ихлас кеше булып калыр ул!

Әсгать СӘГЫТДИНОВ.
Азнакай

Шигърият

Фәридә ШАКИРОВА

СОЛДАТ ХАТЫННАРЫНА

Сугыш ветеранын күргән саен,
Сез мөлдерәп карап торасыз.
Бу мизгелдә гүя, җанны әчеттереп,
«Безнекеләр кайда?» – дип тә сорарсыз.

Сезнекеләр яу кырында калган,
Әллә ятып, әллә күмелеп.
Иманнарын алар байрак итеп алган
Сез яшәсен өчен сөенеп!

Гомер озынлыгы сагышларны
Алар кайтып өзә алмады.
Толлык, ятимлекне күпләр кичерсә дә,
Ватаныбыз ятим калмады.

Дошман аяк асларына төшмәгәнгә,
Ил-йортыбыз түгел җәберле.
Җиңү өчен исәннәр дә кирәк! –
Шуңа алар һәрчак кадерле.

Коллык богауларын чигендерде
Күпне күргән солдат башлары.
Үзләренә ялгышып та әйтмик
Хөрмәт сүзләреннән башканы!

КАРТАЮ

Картайгансың, диләр
күптән күрмәгәннәр,
Җыерчыклар баскан йөземне.
Авырлыкка чыдам идек элек,
Әллә инде бетте түземең?

Картаерга вакыт инде безгә,
Рәхәт-кадер никтер соңлагач.
Михнәт өлешләре күп әлякте,
Бәхет кошы тотып тумагач.

Сынауларның каты сандалында
Төелдек без чуен шикелле.
Тормыш арбасына бер җигелгәч,
Гамьсез яшәүләрең икеле.

Инде менә зиһен сандыкларын
Акыл белән шыплап тутырдык.
Тик яшьлеккә кире кайтып булмый,
Якорь салып, тирән утырдык.

Рәхәт була, нәни шатлыкларны
Җыя барып, җанга беркетсәң;
Яшәү ямен бүгенгедән эзлә,
Картаям, дип, әгәр үкенсәң.

Үткәннәрне уйлап хафаланма,
Киләчәге әле билгесез.
Тормышыңның якты һәр мизгеле
Кысыр чәчәкләргә биргесез!

ТУГАН ЯГЫМА

Ялан тәпиләрем пеште туфрагыңда,
Йөзем янды кырыс җилеңдә.
Мин гади бер ятим бала идем
Яраланган туган җиремдә.

Язмыш мине бәргәләгән чакта,
Куеныңа алып җылыттың.
Күңелемә дәва алыр өчен,
Кырларыңнан сихри моң оттым.

Бактың исә, баскан туфрагымның
һәр карышы изге икән бит.
Шуны аңламаган ваемсызлар
Җелегенә төшеп җиткән бит.

Җәрәхәтле елга кырыйлары
Әрнеп бага безнең күзләргә.
Химикатлар кырган тургайларның
Моңын калды сагынып эзләргә.

Кадер-хөрмәт кәтеп, хуҗа көтеп,
Сыкрап арган җирнең авазын
Ишетергә тиеш идек лә без,
Гамьсез булып нигә соңладык?!

Килмәсен лә безгә чарасыздан
Җирне кочып тетрәп елар чак.
Өмет утын сүндермәгән өчен,
Җанга якын ямьле туган як!

САГЫНАМ, ӨЗЕЛЕП САГЫНАМ...

Синең турында мәдхия көйләргә һәм Аллаһыбызга дога кылып, синең рухыңа ирештерүне сорарга гына калды. Сине, Харис, гаиләң – хатының, 5 балаң, 5 кияү-киленең, 13 оныгың – бик сагына, өзгәләнә-өзгәләнә юксына. Иң кечкенә оныкларың да, нәни кулларын күтәреп, синең рухыңа дога кыла.

Курса-Почмак авылында гомер иткән Харис Мөхәммәдиевнең хезмәт юлы: яшь галим-агроном, колхоз рәисе, төзелеш инженеры, авыл ветераннар советы рәисе. Ул балаларның яраткан әтиләре булды. Бишесен дә кадерләп үстерде, барысын да югары белемле итте. Ике кызыбыз, бер улыбыз әтиләре укыган авыл хуҗалыгы институтында белем алды. Хәзер инде үзләре әти-әни булдылар.

Харис – сугыштан соң туган бала. Әтисе Фәтхерахман, авыр сугыш юлларын үтеп, әсирлектә газап чигеп, туган ягына исән-сау кайту бәхетенә ирешә. Хатыны Фәхирә, ире сугышка киткәндә, 4 бала белән кала. Сугыштан соң тагын ике бала өстәлә. Төпчегенә Фәтхерахман исемне үзе сайлый. Бик сөенеп: «Улыбыз Харис булыр, җир кешесе булып, үз яныбызда калыр», – ди. Харис шук малай була. Менә шул шуклыгы үзенә зыян китерә. Уң күзенә тимер ук кадала. Бу яра төзәлеп бетәр-бетмәс яңадан кара кайгы – әнисе вафат була. Бала күңеле яшьтән үк чыныга. Балаларны үги әни Рәхимә тәрбияләп үстерә. Безнең балаларга да яхшы әби булды ул. Урыны оҗмахта булсын.

Харис балачактан ук авырлыкларга түзеп, тормышны аңлап үсә. Үҗәт тырышлык анда көчле була. Мәктәптә дә сәләтле укучылар рәтендә йөри. Курса-Почмак авылының оста гармунчысы булып китә. Казан авыл хуҗалыгы институтының агрономия бүлеген тәмамлап, «галим-агроном» белгечлеге алып, туган ягына эшкә кайта. Колхозда югары белемле беренче белгеч була. Авыр сынаулар аша узарга туры килә аңа. Корылык килгән елларда уңыш булмый, терлеккә азык җитми. 25 яшьлек яшь агрономны Ульяновск якларына салам әзерләргә җибәрәләр. Эшне Харис оештырырга тиеш була. «Менә шунда чын тормыш мәктәбен үтеп кайттым мин», – дип язган ул.

Эшли башлавына нәкъ 5 ел тулгач, Харисны «Фрунзе» колхозына рәис итеп куялар. 28 яшьлек колхоз рәисенә, билгеле инде, җиңел булмый. Ул вакыттагы акча белән колхозның 2 миллион 800 мең сум бирәчәге дә була. Эшли башлаганда хуҗалык идарәсе Иске Масрада иде. Авылга керергә юллар юк. Батып-чумып ятып, никадәр вакыт, ягулык әрәмгә киткән. Укучы балалар да Кесмәс аша салынган асылмалы басма аша йөрделәр. Язын ул басманы да су баса. Укучы балалар батып менә башлагач, мәктәпләрдә каникул була иде. Менә шуңа күрә дә зур күперләр салып, юлларны күтәрттеләр, таш җәйделәр. Алга карап эшләгән җитәкче өчен төзелеш эшләрен бөтен киңлегенә җәелдерү кирәк булды. Акрынлап районда безнең колхозны «таный» башладылар.

Шушы елларда якташ язучыбыз Гариф Ахунов, Фәрваз Миңнуллин, Гәрәй Рәхим дә безнең колхозда булдылар. Язар әйбер табып, бик ошатып киттеләр. Гариф Ахунов җир-суның язмышын безнең якларда, ягъни безнең колхозда бик уңай бәяләде. Харис турында «Ватаным Татарстан» газетасына (ул вакытта «Социалистик Татарстан») бик матур, эчтәлекле мәкалә язды. Сезгә дә мәкаләнең бер өлешен тәкъдим итәм.

«– Биредә халык теләп яшиме?

– Теләп яши, яратып яши. Берәү дә китми. Беренчедән, без бит яхшы терлек фермалары күпләп төзедек. Эшне җиңеләйтә торган җайланмалар көйләдек. Көянтә-чиләк белән барда-ачыткы ташу, кул белән тирес чыгару бетерелде. Димәк, авылда халыкка эш бар. Икенчедән, мондый матур чишмәләре, тал-тирәкләре, чыр-чу килеп сайрар кошлары булган икенче бер урынны каян эзләп табасың».

Нәкъ тә шушы мәкаләдә әйтелгәнчә булды. Харис туган ягын, аның табигатен, кешеләрне яратты. Халык белән аңлашып яшәде. Социаль яктан авыр хәлле, колхозда хезмәт куйган абый-апайларга, яшь өйләнешүчеләргә колхоз хисабыннан 25ләп йорт төзелде. Хисап җыелышларында, бәйрәмнәрдә кочак-кочак бүләк өләштеләр. Шәт, халык боларны да, башка зур эшләрне дә онытмагандыр.

1991 елда Хариска эштән китәргә туры килде. Кемнәрдер гаиләсенә зыян саларга теләде. Ә Харис гаиләсен бар нәрсәдән дә өстен күрде. Алга таба да ул төзелеш эшләрен алып барды. Йортларга газ кертүне алгы планга куйды. «Авыл йортларына газ кертүне тизләтүдә Мөхәммәдиев Харисның хезмәте зур булды», – дип яздылар район газетасына.

Эшләгән эшләре бик күп. 4 авылда да аның аяк баскан эзләре, тир түккән басу-кырлары, төзеткән биналары һәм, иң мөһиме, ул яраткан, аны хөрмәт иткән, «безнең Харис» дип искә алып торган халкы – колхозчылары бар һәм Аллаһыма мең шөкер, балалары, оныклары бар. Эшен дәвам иттерүче уллары бар.

Лимара МӨХӘММӘДИЕВА.
Арча районы, Курса-Почмак авылы

99 ел 9 көн кебек кенә үткән

Шәмбалыкчы авылында гомер итүче сугыш һәм хезмәт ветераны Зиннәт ага Хәйруллин 99 яшьлек гомер бәйрәмен каршылады.

Зиннәт абыйның хәтеренә, камил акылына, төгәллегенә сокланырлык. Аның һәр җөмләсе төзек, мәгънәле һәм тулы. Вакыйгалар, мәгълүматлар төгәл, ачык, аңлаешлы. Тормышны сөеп, яратып, һәр көненнән тәм табып яши ул. Уллары, оныклары аны кайгыртып кына тора. Кышларны Казанда уздырса да, авылда ул – үз һәм хөрмәтле кеше. Туган көне белән котлаучылар да күп булды ветеранны. Район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Гөлүсә Галләмова район башлыгының котлауларын ирештерде.

– Тормышта тирән эз калдырган, ут-сулар кичкән аксакал сез! Яшьләргә бар яктан да үрнәк булып торасыз. Тагын да олы гомер бәйрәмегезне каршыларга язсын, – диде ул.

Зиннәт абый 1941 елның август аенда армиягә юл ала. Мәскәү, Калуга, Смоленск, Брянск өлкәләрендә, Белоруссия, Польша җирендәге бәрелешләрдә катнаша, Кенигсбергны азат итү вакыйгасының шаһиты була.

– Бик авыр, катлаулы юл үттек. Кырда урак урганда, сугыш башлану хәбәре таралды. Илебез азатлыгы өчен гомеребезне дә кызганмадык. Яшьләр дә Ватанны яратсыннар, хезмәт сөючән булсыннар иде, – ди ветеран.

Зиннәт абый – озак еллар дәвамында яшь буынга белем һәм тәрбия бирүгә зур өлеш керткән шәхес. РСФСРның Мәгариф отличнигы, «Татарстан Республикасының атказанган укытучысы» исеменә лаек булган.

Тынгысыз күңелле, мәдәниятне, сәнгатьне үз иткән Зиннәт абый Фәхри Насретдинов һәм Бану Вәлиева музеен оештыруга зур өлеш керткән. 20 елга якын музейны җитәкләгән. Хезмәт елларында күп кенә республикакүләм фәнни-гамәли конференцияләрдә, бәйгеләрдә катнашкан. Күңеле тулып ташыганда, Зиннәт абый кулына каләм ала. Ул – район газетасының һәм республика басмаларының актив хәбәрчесе дә.

– Матур гомер юлы уздым. Бер минутны да әрәм үткәрмәскә тырыштым. Хезмәтем тынгысыз булса да, нәтиҗәле булды. 99 ел 9 көн кебек кенә узган да киткән, – ди аксакал.

Ләйлә ИСКӘНДӘРОВА.
Апас

ҮЗЕМ БҮЛӘК МИН!

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

– 55 ел гомер иткәндә төрле хәлләр булды. Бер-беребезгә терәк, ярдәмче булдык. Авыр чакларда ул – миңа, мин аңа ярдәм иттек. Барысын бергә, бер уйда, бер фикердә уздырдык. Мин тормышымнан бик канәгать, – ди Фәрит абый.

Наилә апа – укытучылар нәселеннән. Шуңа да, колхозда эшләү белән берләттән югары белем алуын да дәвам иттерә. Хезмәт юлын Дәвеш мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты укытучысы буларак башлап җибәрә. Аннан 30 ел Апас урта мәктәбендә балалар күңелендә ана теленә мәхәббәт тәрбияли.

– Тормышның төрле чагы була. Савыт-саба да шалтырамый тормый. Аны җайлап, үз урынына урнаштыра белү кирәк. Татулык күбрәк хатын-кыздан тора, – ди Наилә апа.

Кәлимуллиннар 2 ир бала тәрбияләп үстергәннәр.

– Әти белән әни гомер буе безгә үрнәк булды. Тулы гаиләдә, тигезлектә үстек. Кешене рәнҗетмәскә, хөрмәт белән карарга өйрәттеләр. Аларга тагын да озын, тигез гомер телибез, – диләр уллары Азат һәм Марат.

Район үзәк хастаханәсенең ак халатлы игелек иясе Эльвира Кәлимуллина әлеге гаиләгә 26 ел элек килен булып төшә. Шул көннән бирле бер сулышта, яхшы мөнәсәбәттә яшиләр.

Ләйлә ШИҺАБИЕВА

«БАЛКЫШ» ФЕСТИВАЛЕННӘН МИЗГЕЛЛӘР

КАЗАННЫҢ ФИЛАРМОНИЯ ЗАЛЫНДА ӨЛКӘННӘР ӨЧЕН КОНЦЕРТ УЗДЫ

ТАТАРСТАН ВЕТЕРАНЫ
Республика ветераннары (пенсионерлары) төбәк иҗтимагый оешмасы советы
һәм «Ватаным Татарстан» газетасының уртак кушымтасы.
Чыгарылыш өчен җаваплы – **Гөлгенә ШИҺАПОВА**. Биткә салучы һәм бизәүче – **Рөстәм МИҢНУЛЛИН.**
Безнең адрес: Казан шәһәре, Театр урамы, 5 й.
Телефон: 8(843) 238-16-88
Электрон адрес: soovp.kzn@tatar.ru